Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Советының илле алтынчы утырышы

Татар Казысы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

16 июнь, 2020 ел № 142

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 6, 7 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2, 4 өлешләре, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Уставының 12 статьясындагы 7 өлеше, 33 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә **Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Казысы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Карар кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, «Вперед» («Алга») газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Кәримуллин